ГЛАВА
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.10.2020 с. Набережные Моркваши 7

Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегендә
гражданнар җыенын үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 нче елның 24 нче октябрендә 9 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы авылы гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2020 нче елның 24 нче октябрендә 10 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы авылы гражданнарының үзара салым җыю мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2020 нче елның 24 нче октябрендә 11 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы авылы гражданнарының үзара салым җыю мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. 2020 нче елның 31 нче октябрендә 09 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы авылы гражданнарының үзара салым җыю мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын билгеләргә.
5. 2020 нче елның 31 нче октябрендә 10 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы авылы гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының бишенче этабын билгеләргә.
6. Халык исемлеген бүлү территориаль билге буенча башкарыла.

1 этап: Яр буе Морквашы авылы, Луговая, Җәлил, Лесная, Солнечная, Дубравная, Молодежная, Полевая, Спорт, Ульяновская, Волгоград урамнарында яшәүчеләр.

2 этап: Яр буе Морквашы авылының Тукай, Сәйдәш урамнарында яшәүчеләр

3 этап: Яр буе Морквашы авылының Мәрҗани, Заречная, Красавин урамнарында яшәүчеләр

4 этап: Яр буе Морквашы авылының Зеленая урамы, Яр буе урамы, Якты урам, Садовая урамы, Күпер урамы, Вишневая урамы, Рябиновая урамы, Веселая урамнарында яшәүчеләр

5 этап: Яр буе Морквашы авылының Отрадная, Нарат, Нагорная ур., Тургенев, Гоголь, Толстой, Лермонтов, Некрасов, Есенин, Пушкин урамнарында яшәүчеләр.

6. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Яр буе Морквашы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә риза булырсызмы:

Яр буе Морквашы авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү

«ӘЙЕ» «ЮК»

8. Халык җыеннарын үткәрергә:

1 этап: Яр буе Морквашы авылы Луговая урамы буенча 1 нче йорт янында

2 этап: Яр буе Морквашы авылы Тукай урамы буенча 8нче номерлы йорт янында

3 этап: Яр буе Морквашы авылы Красавин урамы буенча 6 нчы йорт янында

4 этап: Яр буе Морквашы авылы Якты урамы буенча 10А йорты янында

5 этап: Яр буе Морквашы авылы Нагорный урамы буенча 16-нчы номерлы йорт янында

9. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Яр Буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы И. Х. Гаязов